**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2016 ел, 22 июнь № 425

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым актларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2004 ел, 17 декабрь, 542 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 22 гыйнвар, 22 нче; 2005 ел, 30 май, 239 нчы; 2006 ел, 2 октябрь, 490 нчы; 2007 ел, 6 апрель, 123 нче; 2008 ел, 8 сентябрь, 640 нчы; 2010 ел, 29 ноябрь, 956 нчы; 2011 ел, 21 июнь, 496 нчы; 2011 ел, 6 декабрь, 1001 нче; 2012 ел, 13 апрель, 304 нче; 2013 ел, 19 гыйнвар, 20 нче; 2013 ел, 12 март, 157 нче; 2014 ел, 8 февраль, 80 нче; 2014 ел, 5 декабрь, 947 нче; 2015 ел, 15 апрель, 254 нче; 2015 ел, 1 декабрь, 911 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәдә:

2.2 пунктта:

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Хезмәт ветераннары өстәмә рәвештә айлык акчалата түләү бирү турында мәсьәләне хәл иткәндә исәпкә алына торган аларның керемнәрен раслаган документлар тапшырырга хокуклы (Россия Федерациясе Пенсия фондында булган керемнәр турында мәгълүматлардан тыш). Хезмәт ветераннары эш бирүче (иминиятләүче) тарафыннан физик зат файдасына күчерелгән түләүләр һәм бүтән бүләкләүләр хакында мәгълүматларны раслый торган документлар тапшырырга хокуклы. Хезмәт ветеранына айлык акчалата түләү билгеләү өчен уртача айлык керемне исәпләгәндә исәпкә алына торган керемнәр төрләре исемлеге әлеге Нигезләмәгә кушымтада күрсәтелгән.»;

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әгәр мөрәҗәгать иткән көндә хезмәт ветераны торак урын һәм коммуналь хезмәтләргә түләүгә субсидия (алга таба – субсидия) алучы булып тора икән, ул керемнәре турында мәгълүмат тапшырудан азат ителә.»;

3.17 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.17. Бердәнбер ата-анага, аның кереме булмаган очракта яисә ата-ананың берсенә, аның кереме булмаган очракта һәм икенче ата-ана хезмәт эшчәнлеген алып барган, яисә пенсионер булган, яисә инвалид баланы (яки I төркем инвалидын, яки дәвалау учреждениесе бәяләмәсе буенча кеше каравына даими мохтаҗ яки 80 яшенә җиткән карт кешене) тәрбияләүне гамәлгә ашырган, яисә 18 яшькәчә биш яки күбрәк баласы булып, билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган затның әлеге Нигезләмәнең 3.6 – 3.9 пунктларында күрсәтелгән документларны тапшырмау, әлеге Тәртипнең 3.6 пунктындагы өченче абзацында күрсәтелгән документлардан тыш, балага айлык пособие билгеләүдән баш тарту өчен нигез булып тора.»;

7.2 пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Хезмәт ветераннары элемтә хезмәтләренә субсидия бирү турында мәсьәләне хәл иткәндә исәпкә алына торган аларның керемнәрен раслаган документлар тапшырырга хокуклы (Россия Федерациясе Пенсия фондында булган керемнәр турында мәгълүматлардан тыш). Хезмәт ветераннары эш бирүче (иминиятләүче) тарафыннан физик зат файдасына күчерелгән түләүләр һәм бүтән бүләкләүләр хакында мәгълүматларны раслый торган документлар тапшырырга хокуклы. Хезмәт ветеранына айлык акчалата түләү билгеләү өчен уртача айлык керемне исәпләгәндә исәпкә алына торган керемнәр төрләре исемлеге әлеге Нигезләмәгә кушымтада күрсәтелгән.»;

9.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9.1. Транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү билгеләү өчен пенсияләре «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» федераль законнар нигезендә билгеләнгән, Россия Федерациясенең һәм (яки) Татарстан Республикасының башка норматив хокук актлары буенча социаль ярдәм чаралары күрсәтүгә хокукы булмаган, Татарстан Республикасында яши торган пенсионерлар (алга таба – пенсионерлар), аларның законлы вәкилләре яки алар ышанычнамә нигезендә вәкаләт биргән затлар (алга таба – гариза бирүчеләр) Үзәкнең үзләре яшәгән урындагы бүлегенә түбәндәгеләрне кертә:

транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү билгеләү турында гариза;

транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү билгеләү өчен гариза ышанычлы зат тарафыннан кертелгәндә, ышанычнамә күчермәсен;

айлык акчалата бирү турында мәсьәләне хәл иткәндә исәпкә алына торган керемнәрне раслаган документлар (Россия Федерациясе Пенсия фондында булган керемнәр турында мәгълүматлардан тыш). Пенсионерларга транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү билгеләү өчен уртача айлык керемне исәпләгәндә исәпкә алына торган керемнәр төрләре исемлеге әлеге Нигезләмәгә кушымтада күрсәтелгән.

Әгәр мөрәҗәгать иткән көндә пенсионер субсидия алучы булып тора икән, ул керемнәре турында мәгълүмат тапшырудан азат ителә.

Документлар күчермәләре законнарда билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган очракта, алар төп нөсхәләрне күрсәтеп тапшырыла һәм Үзәк бүлеге белгече тарафыннан раслана.

Гариза бирүчеләр гариза белән мөрәҗәгать иткәндә гариза бирүченең шәхесен таныклаучы документ күрсәтә һәм банкта яки бүтән кредит оешмасында ачылган шәхси исәп счеты реквизитларын бирә.»;

9.3, 9.4 пунктларда «9.2 пунктта» сүзләрен «9.2, 9.11 пунктларда» сүзләренә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү турында» 2006 ел, 24 март, 126 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел, 3 июнь, 370 нче; 2009 ел, 6 апрель, 203 нче; 2010 ел, 13 июль, 553 нче; 2012 ел, 23 февраль, 153 нче; 2013 ел, 12 март, 157 нче; 2014 ел, 25 август, 611 нче; 2015 ел, 23 сентябрь, 701 нче; 2015 ел, 1 декабрь, 911 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәдә:

2.2 пунктта:

җиденче һәм сигезенче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә ТКХ түләү буенча социаль ярдәм чараларына хокуклы хезмәт ветераннары (алга таба – хезмәт ветераннары) субсидия-ташламалар бирү турында мәсьәләне хәл иткәндә исәпкә алына торган аларның керемнәрен раслаган өстәмә документлар тапшыра (Россия Федерациясе Пенсия фондында булган керемнәр турында мәгълүматлардан тыш). Хезмәт ветераннары эш бирүче (иминиятләүче) тарафыннан физик зат файдасына күчерелгән түләүләр һәм бүтән бүләкләүләр хакында мәгълүматларны раслый торган документлар тапшырырга хокуклы. Хезмәт ветеранына субсидия-ташлама билгеләү өчен уртача айлык керемне исәпләгәндә исәпкә алына торган керемнәр төрләре исемлеге әлеге Нигезләмәгә кушымтада күрсәтелгән.

Әгәр мөрәҗәгать иткән көндә хезмәт ветераны торак урын һәм коммуналь хезмәтләргә түләүгә субсидия (алга таба – субсидия) алучы булып тора икән, ул керемнәре турында мәгълүмат тапшырудан азат ителә.».

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында балага айлык пособие түләү турында» 2002 ел, 18 гыйнвар, 14 нче карары үз көчен югалтуын танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры — И.Ш.Халиков